Зур Кукмара авыл җирлеге Советы

Карар

2021 елның 23 ноябре №29

Зур Кукмара авыл җирлеге Советының 2019 елның 28 ноябрендәге 26 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлеге Уставының 22 нче статьясы нигезендә Зур Кукмара авыл җирлеге Советы карар бирде:

Зур Кукмара авыл җирлеге Советының 2019 елның 28 ноябрендәге 26 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 1.7 пунктының өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- җирлек составына керүче торак пунктта (яисә аның территориясенең бер өлешендә), әлеге торак пункт территориясендә (яисә аның территориясе өлешендә) үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча;»

2. Нигезләмәнең I бүлеген түбәндәге эчтәлекле бүлек белән тулыландырырга:

«Торак пункт территориясененең бер өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены

1.10. Гражданнар җыены авыл җирлеге составына керүче торак пункт территориясе өлешендә торак пунктның әлеге өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелергә мөмкин.

Мондый җыен авыл җирлеге Советы тарафыннан, торак пункт территориясенең кимендә 10 кеше яшәгән тиешле өлешендә яшәүчеләр инициативасы белән чакырыла.

1.11. Гражданнар җыены үткәрелә торган торак пункт территориясе чикләре җирлек Советы карары белән торак пункт территориясенең күрсәтелгән өлешендә яшәүчеләрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл иткәндә гомуми мәнфәгатьләре критерийларыннан чыгып билгеләнә.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җирлек башлыгы Р.Р. Хәнәфиев